КАРАР

26 ноябрь 2019 ел №2

Гражданнарнын узара салым акчаларын керту һәм куллану мәсьәләсе буенча Кукмара муниципаль районының Түбән Өскебаш авылы жирлегендә гражданнар жыены нәтижәләре турында.

“Россия Федерациясендә жирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” *2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнын* 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 25.11.2019 һәм 26.22.2019 елда түбәндәге сорау буенча узган гражданнар жыеннары нәтиҗәләре белән гражданнар жыены беркетмәсе төзелде: «Кукмара муниципаль районының Түбән Өскебаш авылы, Түбән Өскебаш авылы жирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, укучыдан һәм студентлардан (курсантлардан), 18 яшькә һәтле 4 һәм аннан артык балалары булган күпбалалы гаиләләрдән, ялгыз әниләрдән, 85 яшь һәм аннан өлкәнрәк гражданнардан тыш, 2020 елда үзара салым кертүгә 500 сум күләмендә риза булырсызмы?

- Түбән Өскебаш авылының Советская урамы буенча юлга вак таш түшәү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; юл салу;
- Түбән Өскебаш авылындагы юлларны кардан чистарту;
-Пожар сүндерү машинасына запчастьләр алу;
-Түбән Өскебаш авылы урамына су кертү;
- Түбән Өскебаш авылындагы артезиан скважиналары өчен насослар алу;
-Түбән Өскебаш авылындагы су скважинасы жиренә киртә тоту(материал сатып алу, договор буенча түләү), проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
-Түбән Өскебаш авылының Советская урамы баганаларына электр энергиясен сакчыл тоту лампочкалары сатып алу, урташтыру, договор буенча түләү;

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар жыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган ,жыенда катнашучылар исемлегенә, 310 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнарның саны 166.
Тавыш бирү нәтижәләре буенча гражданнар жыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен 166 гражданнар жыенында катнашучы тавыш бирде; "Юк" позициясе өчен гражданнар жыенында 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар жыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Түбән Өскебаш авыл жирлегендә гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес.
2. Сорау буенча карарны танырга: «2020 елда үзара салым кертүгә Кукмара муниципаль районының Түбән Өскебаш авылы, Түбән Өскебаш авылы җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, укучыдан һәм студентлардан (курсантлардан), 18 яшькә һәтле 4 һәм аннан артык балалары булган күпбалалы гаиләләрдән, ялгыз әниләрдән, 85 яшь һәм аннан өлкәнрәк гражданнардан тыш, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешеп торасызмы:

- Түбән Өскебаш авылының Советская урамы буенча юлга вак таш түшәү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; юл салу;
- Түбән Өскебаш авылындагы юлларны кардан чистарту;
-Пожар сүндерү машинасына запчастьләр алу;
-*Түбән Өскебаш авылы урамына су кертү;*
- Түбән Өскебаш авылындагы артезиан скважиналары өчен насослар алу;
-Түбән Өскебаш авылындагы су скважинасы җиренә киртә тоту(материал сатып алу, договор буенча түләү), проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
-Түбән Өскебаш авылының Советская урамы баганаларына электр энергиясен сакчыл тоту лампочкалары сатып алу, урташтыру, договор буенча түләү;

«РИЗА» «КАРШЫ»

-кабул ителде.

3.“Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтын урнаштыру юлы белән гражданнар җыенының нәтиҗәсен бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырырга: www.pravo.tatarstan.ru,.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Авыл җирелеге башлыгы Н.М.Мөхәммәтжанов